| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

21.02.2024 ел　　　Баулы шәһәре　　　№30

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 апрелендәге 81 номерлы “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Ситуацион үзәген барлыкка китерү турында” карарына (2023 елның 23 мартындагы 78 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 2 октябрендәге 894 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгенә керүче оешмаларында эшләүче ситуацион үзәкләрен функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә типлаштырылган таләпләр Стандартын һәм Татарстан Республикасы бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрен аккредитацияләү турында Нигезләмәләрне раслау турында” карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 апрелендәге 81 номерлы “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Ситуацион үзәген барлыкка китерү турында” карарына (2023 елның 23 мартындагы 78 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3 пунктта:

3.2.пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Ситуацион үзәк администраторы итеп - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигын;

мәгълүматны саклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларына керүен оештыру өчен җаваплы – Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге начальнигы;»;

3.3. пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә өстәмә кертергә:

«3.3. Муниципаль дәрәҗәгә таркатылган Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч мәгълүматларны җыюны оештыру өчен җаваплы зат – Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарын;

муниципаль дәрәҗәгә таркатылган Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен мониторинглау һәм башлангыч мәгълүматларны җыю өчен җаваплы зат – Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигын.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының  икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигына:

- өстәмә функцияләрне исәпкә алып, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр әзерләргә һәм кертергә;

- Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларын саклау урынын билгеләү;

- Кварталга бер тапкыр, Баулы муниципаль районы Башлыгына Ситуацион үзәк эшчәнлеге турында хисап тапшырырга.

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге начальнигына:

- өстәмә функцияләрне исәпкә алып, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр әзерләргә һәм кертергә.»;

6 пунктта:

түбәндәге эчтәлектәге абзац белән өстәмә кертергә:

«Җаваплы структур бүлекчәләргә паспортларында күрсәтелгән модельләрнең актуальләшү чорына ярашлы рәвештә, мәгълүмати-аналитик модельләрне актуаль хәлдә тотуны тәэмин итәргә.»;

күрсәтелгән карар белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Ситуацион үзәге турында нигезләмәдә:

1 бүлек «Гомуми нигезләмәләр»:

1.2.пунктында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ситуацион үзәк администраторы – Ситуацион үзәкнең эшчәнлеген тәэмин итүче, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы;»;

унынчы абзац белән түбәндәге эчтәлектә туландырырга:

«мәгълүматны саклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның ситуация үзәгенең мәгълүмати ресурсларына керүен оештыру өчен җаваплы – Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге начальнигы.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ситуацион үзәкнең эшен оештыру

3.1. Ситуацион үзәкнең администраторы булып Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы тора.

3.2. Мәгълүматны саклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның ситуация үзәгенең мәгълүмати ресурсларына керүен оештыру өчен җаваплы булып Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге начальнигы тора.

3.3. Ситуацион үзәк администраторы контрольлек итә:

- Ситуацион үзәкне эксплуатацияләүдә;

- Ситуацион үзәкнең агымдагы эшчәнлеген һәм үсешен тәэмин итүдә.

Мәгълүматны саклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның ситуация үзәгенең мәгълүмати ресурсларына керүен оештыру өчен җаваплы:

- Ситуацион үзәкнең мәгълүматларын саклау буенча эш алып бара;

- Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән, Ситуацион үзәкнең мәгълүмати куркынычсызлык сәясәте нигезендә, кулланучыларга Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларына керү мөмкинлеген бирә;

- Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурслар реестрын һәм мәгълүмати-аналитик модельләрен үзәкләштерелгән алып баруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров